КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 август г.Казань № 1020

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 2 октябрь, 945 нче карары белән расланган Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 2 октябрь, 945 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 декабрь, 1310 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2.6. Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары түбәндәгеләр:

а) контрольдә торучы зат тарафыннан узган кварталда сатып алынган, федераль махсус маркалар белән тамгаланган алкоголь продукциясе күләмен 20 процентка һәм аннан да күбрәк арттыру, мондый зат тарафыннан алкогольле продукцияне сату күләмен шул ук вакытта 5 процентка һәм аннан да күбрәк процентка арттырмаганда (этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм аларның әйләнеше күләмен исәпкә алуның бердәм дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы (алга таба - бердәм мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә;

б) алкогольле продукция сату белән бәйле булмаган нигезләр буенча (бердәм мәгълүмат системасы белешмәләре нигезендә) календарь ай дәвамында алкогольле продукция күрсәтелгән чорда контрольдә тотучы зат тарафыннан гамәлгә ашырылган алкогольле продукциянең гомуми күләменең 20 процентыннан артыграк күләмдә юкка чыгару;

в) федераль махсус маркалар белән тамгаланырга тиешле алкогольле продукцияне контрольдә тотучы зат тарафыннан кире кайтаруларны яисә алкогольле продукцияне кабул итүдән баш тартуларны бердәм мәгълүмат системасында теркәү, кире кайтарылган яисә кабул итүдән баш тартылган алкогольле продукциянең гомуми күләме шул ук кварталда сатып алынганнан 10 процентка арткан очракта;

г) бердәм мәгълүмат системасында контрольдә тотучы зат тарафыннан сыра һәм сыра эчемлекләре, сидр, пуар, бал кире кайтарылуларны йә кабул итүдән баш тартуларны теркәү, мондый продукцияне кире кайтару яисә кабул итүдән баш тарту күләме 10 проценттан арткан очракта;

д) сыраның һәм сыра эчемлекләренең, сидрның, пуареның, әче балның контрольдә тотыла торган заты тарафыннан шул ук квартал өчен мондый алкоголь продукциясен сатып алуның гомуми күләменең 10 процентыннан артыграк булуы шарты белән кабул итү (бердәм мәгълүмат системасы белешмәләре нигезендә);

е) сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, әче балны ваклап сату күләменең 10 процентына һәм аннан да күбрәк күләменә мондый продукцияне ваклап сату күләме белән календарь ай дәвамында бердәм мәгълүмат системасы белешмәләренә ярашлы рәвештә идентификация чаралары (алга таба - мониторинг системасы) тарафыннан мәҗбүри маркировкаланырга тиешле товарлар әйләнешен мониторинглауның дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә нигезләнеп;

ж) квартал дәвамында бердәм мәгълүмат системасында алкоголь продукциясен ваклап сатуга һәм (яисә) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуга лицензиясе булган оешмалар тарафыннан маркалы алкоголь продукциясен сатып алу һәм (яисә) ваклап сату турында мәгълүмат булмау;

з) мәҗбүри маркировкага тиешле сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, әче балны ваклап сату объектында сату турында мәгълүматлар,элек әйләнештән чыгарылган товарны маркировкалау кодын күрсәтеп, календарь ай дәвамында мониторингның мәгълүмат системасында сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, әче балны сату буенча уртача үлчәнгән күләмнең 50 проценттан артыгы күләмендә, шул ук календарь айда ваклап сату объектында булуы;

и) мониторингның мәгълүмат системасында булмаган маркировка кодларын күрсәтеп, календарь ай дәвамында мониторингның мәгълүмат системасында ваклап сату объектында сыраны һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, балны сату турында шул ук календарь айда Россия Федерациясендә ваклап сату объектында сыра һәм сыра эчемлекләре, сидр, пуаре, әче бал сату күләменең 25 проценттан артыгы күләмендә мәгълүматлар булу;

к) бер квартал дәвамында федераль махсус маркалардагы бер үк төрле штрихлы кодлы алкоголь продукциясен ваклап сату факты турындагы белешмәләрнең бердәм мәгълүмат системасында 10 һәм аннан да күбрәк тапкыр теркәлүе;

л) сыра һәм сыра эчемлекләре, сидра, пуаре, әче бал кулланучылар савтында сатып алынган сыраның һәм сыра эчемлекләренең гомуми күләменең

50 процентыннан артыгы күләмендә, сидр, пуаре, әче бал квартал йомгаклары буенча бердәм мәгълүмат системасы мәгълүматларына нигезләнеп сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, әче балны ваклап сатуны контрольдә тотучы зат тарафыннан сатып алу (махсуслаштырылган азык-төлек кибетләрендә);

м) 8.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр һәм 22.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр әлеге продукцияне ваклап сату объектында календарь көн дәвамында сатылган алкоголь продукциясенең гомуми күләменнән бердәм мәгълүмат системасы мәгълүматларына нигезләнеп, алкоголь продукциясенең 90 процenttан артыгын сату факты.».

2. Бу карар (бу карарның 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы унынчы һәм унберенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин